**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

23 октябрь 2023 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2023 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урам 2-46нчы йортларда яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2023 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урам 1-59нчы йортларда, Үзәк тыкрыгы, Яшьләр урамында яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем

инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;

Әхмәт авылында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова